| | | |
|---|---|---|
| «Рассмотрено»<br>Руководитель МО<br><br>Хуз Р.Т. Хузина<br>Протокол № 1<br>от «23» 08 2017 г. | «Согласовано»<br>Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»<br>________Яковлева М.В.<br>от «23» 08 2017г. | «Утверждаю»<br>Директор ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»<br>________Беспалова Т.В.<br>Приказ № 43<br>от «__» 08 2017 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Гайнуллиной Гульназ Фоатовны, к.п.н.
Ф.И.О., категория

по татарскому языку, 11А; 11Б
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

2017 - 2018 учебный год

**эш программасы**

**Укытучы: доц. Гайнуллина Гөлназ Фоатовна**

**Аңлатма язуы**

Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

1. Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон (2012 нче елның 29 нчы декабрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013 нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә);

2. РФ “Мәгариф турында”гы Законының 7 нче маддәсе.

3. “Мәгариф турында” ТР Законы (1997 ел, 2 июль. Үзгәрешләр – 2012 ел, 21 июнь).

4. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль).

5. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь).

6. "Белем бирүнең вакытлы дәүләт стандартларын раслау турында" ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы №499/09, 04.03.2009 ел.

7. Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең вакытлы дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.

8. «2014-2020 нче елларда ТР сы дәүләт телләрен һәм ТРның башка халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТРсы дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 нче елның 25 нче октябреннән 794 нче карары)

9. Лицейның белем бирү программасы.

10. “Н.Лобачевский исемендәге Академик лицей” ның укыту планы.

11. “Н.Лобачевский исемендәге Академик лицей” ның “Эш программалары” буенча локаль акты

12. Коммуникатив технология нигезендә рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы. 1-11 нче сыйныфлар , Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Төзүчеләр: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны программада күрсәтелгәнчә: елга барысы – 34 сәг., атнага – 1 сәг.**

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары:**

• татар теленең һәм әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны турында мәгълүмат бирү;

• татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белү;

• татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктицион нормаларын белү һәм, аларга нигезләнеп, телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;

• аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын һәм антонимнарын төгәл һәм урынлы куллана белү;

• татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белү;

• гади һәм кушма җөмләләрнең төрен белү;

• татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп, оештыру осталыгына ия булу;

• татар һәм рус телләре арасындагы тарихи, мәдәни бәйләнешләр турында белү;

• төрле чыгаганклардан (фәнни-популяр текстлар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б.) файдаланып, кирәкле мәгълүматны таба һәм башкаларга телдән яки язмаса җиткерә алу;

• мәдәниара аралашу ситуацияләрендә әңгәмә кора алу;

• тиешле (3500 - 4000 сүз) күләмдә татар сүзләрен яттан белеп, аларны телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллана белү. рус һәм татар телендәге әсәрләрнең уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрне чагыштырып бәяләү; татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикерен белдерү, аларга бәя бирү; татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү; 3 диалогта яисә бәхәстә катнашып, үз фикерен исбатлый белү.

**Укыту предметына гомуми аңлатма**

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары:

-укучыларның гомуми белем мәктәбендә үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү һәм тирәнәйтү;

-тел күренешләрен танып белергә, чагыштырырга, гомумиләштерергә күнектерү;

-татар телен халыкның рухи, әхлакый, мәдәни хәзинәсе буларак аңларга ирешү;

-татар әдәбиятыннан алган белемне сөйләм телендә куллана белү; -алган белемнәрне җанлы аралашу шартларында кулланырга өйрәтү;

-укучыларның орфографик, пунктацион граматолылык дәрәҗәсен камилләштерү.

**Эш программасы статусы**

Программа нигезенә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды, ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган «Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту программасы» (Казан, «Мәгариф»,2010ел), 11 нче сыйныф өчен Р.З.Хәйдәрова тарафыннан эшләнгән (Казан, Мәгариф, 2010), ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслек һәм рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева әзерләгән кулланмага нигезләнеп төзелде.

**Эш программасы структурасы**

Татар теленең эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны.**

Укыту планында 11 нче сыйныфта татар теленнән атнага 1 сәгать вакыт бирелә.

Татар әдәбиятыннан тематик планны рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (Программа нигезенә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды, ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган «Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту программасы» (Казан, «Мәгариф»,2010ел), 11 нче сыйныф өчен Р.З.Хәйдәрова тарафыннан эшләнгән (Казан, Мәгариф, 2010), ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслек һәм рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева әзерләгән кулланмага нигезләнеп төзелде.

Программада 34 сәгать каралган. 11 нче сыйныф дәреслеге коммуникатив технология нигезендә төзелгән. Дәреслектә дәресләр челтәре цикллыкка корылган. Цикл – текстны укып, аның эчтәлеген диалогик , монологик, ягъни мөстәкыйлҗ сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик яктан катлаулыгына, текстның күләменә бәйле.

**Укыту предметының төп эчтәлеге**

Татар теленең эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән. ТӨП гомуми белем бирү һәм урта гомуми белем бирү мәктәбендә укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен камилләштерү, татар теленнән системалы фәнни белем бирү белән беррәттән, татар дөньясы, татар әдәбияты турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү, ягъни укучыларның коммуникатив компетенцияләрен үстерү гомуми максат итеп билгеләнә. Моңа ирешү өчен, татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү; сөйләмне тыңлап аңлау күнекмәләрен тирәнәйтү; бирелгән ситуация буенча диалогик яки монологик сөйләм булдыруга ирешү; карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрлардагы текстларны аңлап уку һәм текстта күтәрелгән проблемаларны төгәл билгеләргә һәм аларга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерергә өйрәтү; татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре һәм әдипләре белән таныштыру юнәлешендә эзлекле һәм нигезле эш алып бару зарур. Төп гомуми белем бирү һәм урта (тулы) белем бирү мәктәбендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) үзара бәйләнештә өйрәтү төп максатларның берсе булып тора. Укучыларда аралашу барышында куелган коммуникатив максатларга ирешү; укылган (тыңланган) текстларның эчтәлеген эзлекле итеп сөйли алу һәм телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыра алу күнекмәләре булдыру иң мөһим эшләрдән саналырга тиеш. Татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп принциплары, методлары, эчтәлеге башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе программасында төгәл билгеләнгән. Төп гомуми белем бирү һәм урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә дә укытучы аңлы- коммуникатив методка нигезләнеп эш итәргә, телгә өйрәтүне гамәли эшчәнлеккә юнәлтергә тиеш. Укучыларның фонетик күнекмәләрен тирәнәйтү өчен, сөйләмне орфоэпик һәм орфографик яктан дөрес оештырырга күнектерү мөһим. Мондый күнекмәләргә ия булганда гына, укучылар татар телендә аралашу барышында ү з фикерләрен төгәл белдерә алалар.

Укучыларның лексик күнекмәләрен үстерү өчен, сүзләрнең мәгънәсен, башка, сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә куллану үзенчәлекләрен гамәли үзләштерүгә игътибарны арттыру зарур. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләренең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да (пешерергә — варитъ, готовитъ, печь; юарга — стиратъ, мытъ), рус телендә эквивалентлары

булмаган сүзләрне (каз өмәсе, карга боткасы) аңлатып бирү дә, сүзләрнең антонимнары һәм синонимнары белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә кулланырга өйрәтү дә әһәмияткә ия. Татар телендә күпмәгънәлелек күренешенең аеруча киң таралуын истә тотып, укытучы сүзнең тиешле мәгънәсен кон- тексттан чыгып аңларга өйрәтүгә аерым игътибар бирергә тиеш. Болай эшләү укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, телдән һәм язма сөйләмне дөрес оештыру өчен нигез булып тора. Укучыларның грамматик күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү төрле сүз төркемнәренең морфологик формаларын, җөмлә калыпларын, тотрыклы сөйләм гыйбарәләрен гамәли үзләштерү һәм аларны аралашуда кулланырга күнектерүдән гыйбарәт. Рус телле балаларга татар телен укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү юнәлешендә максатчан эш алып барырга кирәк, чөнки сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, сөйләм барлыкка килә. Димәк, мондый күнекмәләр җөмләнең, диалогик яки монологик хәбәрләмәнең, бәйләнешле текстның грамматик дөреслеген һәм төгәллеген тәэмин итәргә тиешләр. Укучыларның ана 5 теле үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы да укытучы игътибарыннан читтә калмаска тиеш, чөнки татар һәм рус җөмләләрендә сүзләрне үзара бәйләү закончалыклары күпкә аерыла, ә бу исә укучыларның сөйләмендә интерферент хаталарга китерә.

Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә (10—11 нче сыйныфлар) укытучы төп игътибарны укучыларның лексик-грамматик белемнәрен гомумиләштерүгә һәм системалаштыруга; телдән һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә, фикер йөртү сәләтен үстерүгә; аларда мөстәкыйльлек, иҗади активлык, әхлаклылык тәрбияләүгә юнәлтергә тиеш. Санап чыккан бурычларны уңышлы хәл иткәндә генә, урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучыларны татар теленнән Бердәм республика имтиханын (БРИ) тапшырырга әзерләп була.

Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары Укуны бәяләү нормасы – 11 нче сыйныфта 95 – 100 сүз. Текстны тулаем аңлап, авазларны һәм сүзләрне дөрес әйтеп, басымны дөрес куеп, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп тиешле тизлектә укыганда “5”ле куела. Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әмма 2 – 3 орфографик хата җибәреп(авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, синтагмаларга бүленештә ялгышу) укыганда “4”ле куела Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, 4-6 тупас орфографик хата җибәреп укыганда һәм уку тизлеге акрын булганда, “3”ле куела Текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып, 7дән артык әйтелеш хатасы җибәреп һәм уку тизлегенә куелган таләпләрне сакламыйча укыганда, “2”ле куела.

Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү

Сүзлек диктанты – 28-33 сүз

Сүзлек диктантын бәяләү

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант – ел башында 95-105 сүз; ел ахырында 105-115 сүз

Контроль диктантны бәяләү

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме: ел башында 150-160 сүз ; ел ахырында 165-175 сүз

Изложениене бәяләү

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.
2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела.

Сочинениенең күләме

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби-иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинение план нигезендә языла. Ике сәгать дәвамында сыйныфта язылган сочиненинең күләме 9 – 11 нче сыйныфларда 18-20 җөмлә. Сочинениене бәяләү 1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)

Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.

Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, 6 орфографик, 6 пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.

Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт— алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация буенча яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, “5”ле куела. Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, “4”ле куела

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, “3”ле куела. Бирелгән ситуация яки тема буенча диалог төзи алмаганда, “2”ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен “5”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган монологик сөйләм өчен “4”ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4-7 хатасы булган монологик сөйләм өчен “3”ле куела.

Өйрәнелгән темага яки бирелгән темага монолог төзи алмаганда, “2”ле куела

**Йомгаклау билгесе**

Йомгаклау билгесе яртыеллык һәм уку елы ахырында куела. Ул, беренче чиратта, укучыларның телдән сөйләм күнекмәләре, бәйләнешле сөйләм төзи белү осталыгы, татар телендә аралаша алу мөмкинлекләреннән чыгып, шул ук вакытта язма эшләрнең нәтиҗәләрен исәпкә алып куелырга тиеш. 6.Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр һәм көтелгән нәтиҗәләр.

**Тел материалын үзләштерүгә таләпләр**

1. Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен гамәли белү.
2. Иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тотып сөйли алу.
3. Хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән әйтә алу.
4. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне, шул исәптән кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес куллана һәм яза белү.
5. Антоним, синоним, омонимнарны аера белү һәм сөйләмдә урынлы куллана алу.
6. Татарча-русча, русча-татарча һәм башка төр сүзлекләрдән файдалана белү.
7. Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендә исемнең тартым категориясе булу һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләре; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы һәм аның аналитик формалар белән бирелеше; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң килүе; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында килеш белән төрләнмәве.

8. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алу.

9. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, кушма җөмләдә тыныш билгеләре.

**11 нче сыйныфта белем бирүнең эчтәлеге**

| № | Сәгать саны | Бүлекләр | Лексика | Грамматика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 11 | Алда юллар, кайсын сайларга? | Күркәм, тир түгү, дөнья тану, кеше характерына хас сыйфатлар, аяныч, дәрәҗә, даһи, куәтле, остаз, гаять, бутамагыз, җаваплы, өлгереш, горурлык, сабырлык, БДИ, кыяфәт, карак, шикле, җинаять, хокук, гадел, нәсел. | Хикәя фигыльнең заман формалары, җөмлә кисәкләре, килешләр, сыйфат фигыльнең заманнары, шарт фигыль, хәл фигыль, зат алмашлыклары, сүз ясагыч кушымчалар, бәйлек сүзләр. |
| 2 | 6 | Татарстан Республикасы | Шартнамә, игълан ителде, чыганак, милли, сынлы сәнгать, саклана, атаклы, тамашачы, шәхес, данлыклы, җитәкчелек итә, вакыйга. | Ия белән хәбәр арасында сызык кую, сан төркемчәләре, билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. |
| 3 | 9 | Гаилә һәм балалар | Шаккату, ияләшә төшү, аерылышу, эндәшми калам, серне ачу, шаярту, хис итү, өйләнешә, көнләшә, барыбер, тәре, кәләпүш, намаз, үкенү, чуар, купшы, казына, интегә, үкенә, кызарта, шашкан музыка, читлек, дога, төнге тормыш, мәрхүмә, фахишә, коточкыч, һәлакәт. | Бәйлек сүзләрнең төрле килешләрдә кулланылышы, билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыль, рәвеш төркемчәләре, җыйнак, җәенке җөмләләр, исем фигыль, туры сөйләм. |
| 4 | 8 | Мәхәббәт – гаиләнең нигезе | Кое, исбатлый, файда, шаян, рәсми, сабыр ит, тырыша, | Инфинитив, боерык фигыль, тезүче һәм иярүче теркәгечләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | үсмер чакта, мәҗлес, вәгъдә, сөй. | |

**Эчтәлекнең темаларга һәм сәгатьләргә бүленеше**

| № | Төп темалар | Барлык | теоретик материал | контроль эшләр, тикшерү күнегүләре | админис. кон.эш. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Алда юллар, кайсын сайларга ? | 11 | 10 | 1 | |
| 2 | Татарстан Республикасы. | 6 | 4 | 1 | 1 |
| 3 | Гаилә һәм балалар. | 9 | 8 | 1 | |
| 4 | Мәхәббәт – гаиләнең нигезе. | 8 | 6 | 2 | |
| | **Барлыгы** | 34 | 28 | 5 | 1 |

| Эш төре | Еллык саны | I чирек | II чирек | III чирек | IV чирек |
|---|---|---|---|---|---|
| БСҮ | 5 | 1 | 1 | 3 | |
| Диктант | 4 | 1 | 1 | 1 | 0 |
| Изложение | 1 | 0 | 1 | 0 | 0 |
| Сочинение | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 |
| Контроль эш | 4 | 1 | 1 | 1 | 0 |

**Календарь -тематик план**

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| **Алда юллар,кайсын сайларга? -11 сәгать** | | | | |
| 1 | Хикәя фигыль | 1 | | |
| 2 | Җөмлә кисәкләре | 1 | | |
| 3 | Килешләр | 1 | | |
| 4 | Сыйфат фигыль | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | “Сез әзерме?” текстындагы лексик-грамматик материал | 1 | | |
| 6 | “Имтихан” әсәрендәге лексик-грамматик материал(1 нче өлеш) | 1 | | |
| 7 | “Имтихан” әсәрендәге лексик-грамматик материал (2 нче өлеш) | 1 | | |
| 8 | Мөстәкыйль эш | 1 | | |
| 9 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.Хаталар өстендә эш. | 1 | | |
| 10 | “Данлыклы Акчуриннар” текстындагы лексик-грамматик материал | 1 | | |
| 11 | “Ак чәчәкләр” әсәрендәге лексик-грамматик материал | 1 | | |
| **Татарстан Республикасы -6 сәгать** | | | | |
| 12 | “Татарстан Республикасы” текстындагы лексик-грамматик материал | 1 | | |
| 13 | Изложение.Гаилә. | 1 | | |
| 14 | Хаталар өстендә эш. | 1 | | |
| 15 | Сан төркемчәләре. | 1 | | |
| 16 | Административ контроль эш. | 1 | | |
| 17 | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль.Хаталар өстендә эш. | 1 | | |
| **Гаилә һәм балалар -9 сәгать** | | | | |
| 18 | Бәйлек сүзләр | 1 | | |
| 19 | “Тапшырылмаган хатлар” әсәрендәге лексик-грамматик материал | 1 | | |
| 20 | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | 1 | | |
| 21 | Диктант “Буран”.Рәвеш төркемчәләре. | 1 | | |
| 22 | Җыйнак, җәенке җөмләләр.Хаталар өстендә эш. | 1 | | |
| 23 | “Әни нинди була?” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | 1 | | |
| 24 | Туры сөйләм | 1 | | |
| 25 | “Сөембикә кыйссасы” хикәясендәге лексик-грамматик материал | 1 | | |
| 26 | Исем фигыль | 1 | | |
| **Мәхәббәт – гаиләнең нигезе - 8 сәгать** | | | | |
| 27 | Диктант “Март” | 1 | | |
| 28 | Хаталар өстендә эш.Инфинитив | 1 | | |
| 29 | Боерык фигыльнең төрләнеше | 1 | | |
| 30 | “Батыр егет” хикәясендәге лексик-грамматик | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | материал | | | |
| 31 | Теркәгечләр | 1 | | |
| 32 | Үткән заман хикәя фигыль | 1 | | |
| 33 | Гомумиләштереп кабатлау. | 1 | | |
| 34 | Контроль эш. | 1 | | |

**Укыту-методик комплекты**

Тематик план Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән "Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен, 1 – 11 нче сыйныфлар)" нигезендә төзелде (2010).

Дәреслек

Татар теле: Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәкт. 11 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Р.З.Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. – Казан: Мәгариф, 2010.

**Өстәмә әдәбият**

Татар теле йомгаклау аттестациясенә әзерләнү өчен кулланма.Рус телендә сөйләшүче укучылар өчен.Казан."Гыйлем" нәшрияты. 2015

**Кулланылган әдәбият**

1. Татар теле йомгаклау аттестациясенә әзерләнү өчен кулланма. Рус телендә сөйләшүче укучылар өчен.Казан."Гыйлем" нәшрияты. 2014.

2. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телле балаларның татар телнннән белемнәрен контрольгә алу буенча биремнәр җыентыгы. Яр Чаллы , 2014 нче ел.

3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К. Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002.- 367б.

4. Хайдарова Р.З., Малафеева Р.Л. Татарский язык в таблицах:Таблицы по татарскому языку для работы с русскоязычными учащимися/ Р.З.Хайдарова, Р.Л.Малафеева. – Наб. Челны, 2005. – 36 с.

5. Бадиков К.Г. Уроки татарского языка / К.Г.Бадиков. – Казань:Татарское кн.изд-во, 1993. – 256 с.

**Интернет-ресурслар**

http://www.ed.gov.ru  Белем бирү буенча федераль агентлык
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.edu. kzn.ru  ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru

http://pedsovet.org  Бөтенроссия интернет-педкиңәшмәсе
http://www.shoolexpo.ru
http://. belem.ru
http://. Tat. Tatar - inform.ru   ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru  ТР электрон газетасы
http://. xat.ru  Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ru   on- line  русча сүзлек
http://. Kitapxane.at.ru    татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru    татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru    татарча текстлар
http://. selet.ru  "Сәләт" яшьләр
http://. Tatarca.boom.ru    татарча текстлар
tatartele 2010.ucoz.ru
tugan-tel.blogspot.com